**СОВЕТ**
**АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 14 нче июне

№ 46-143

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 39-124 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 14.11.2023 №39-124 карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче өлешнең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурыч булу;»;

1.2. 1 нче өлешнең 4 нче пункты карарларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;»;

1.3. Карарның 1 өлеше түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт белән тулыландырылырга:
«5) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы                                                  Д.С. Гайнуллин